ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.02.2021 Олы Кайбыч ав. № 61

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартлары турында» 2020елның 30 апрелендәге 227 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 18 декабрендәге 1148 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 30 апрелендәге 227 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
пункт 1 приложения дополнить предложением следующего содержания:

«Арендатор 2020 елның 1 апреленә торышы буенча алар турында мәгълүмат Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында йә Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында бирелә торган икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре буенча билгеләнә.»;

3 пунктта:

беренче абзацта «2020 елның 1 октябренә кадәр» сүзләрен «2021 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) кичектерү тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә бирелә;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе О. Д. Макаровага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров